Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 3 марты　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　42№

Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге «Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 151 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы, шулай ук Россия Федерациясе Генераль прокурорының 2007 елның 17 сентябрендәге «Прокуратура органнарының хокук иҗат эшчәнлеге һәм дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне яхшырту турында» 144 номерлы боерыгы нигезләнеп, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 85,86 статьясы нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге «Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 151 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне хупларга.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы:　　　　　　　А. Ф. Никошин

Совет Алькеевского муниципального района РТ

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2021елның 3 мартындагы 42 номерлы карарына кушымта

**Әлки муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:
«16) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;»